2026 елда Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Сөләй авылы жирлеге Сөләй авылы гражданнарның үзара салымын кертү турында

ГРАЖДАННАР ЖЫЕНЫ КАРАРЫ

29 ноябрь 2025 ел № 8

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары нигезендә «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Сөләй авыл җирлегенең Сөләй авылы гражданнар жыены карар кабул итте:

1. 2026 елда Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Сөләй авыл җирлегенең Сөләй авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән 500 сум күләмендә үзара салым кертергә, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнардан, махсус хәрби операциядә катнашуга бәйле рәвештә хәрби хезмәт узу турында контракт төзегән гражданнардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлтергә: торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзүне, ремонтлауны, карап тотуны (вак таш түшәүне).

3. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, Сөләй авылы, Совет урамы, 53А йорт территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә Әлмәт муниципаль районы сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

Гражданнар жыенында рәислек итүче,
Сөләй авыл җирлеге башлыгы А.З. Бикбаев